СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2025 г.Лениногорск № 33

Лениногорск муниципаль районы Советының 2025 елның 10 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы территориясендә даими рәвештә җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның гаиләләренә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр яны җир транспортында балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү тәртибе»нә үзгәрешләр кертү турында

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2025 елның 10 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы территориясендә даими рәвештә җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның гаиләләренә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр яны җир транспортында балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү тәртибе»нә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның исемендә «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБМУ» сүзләреннән соң «, шулай ук «Лениногорск балалар йорты» ДБУнән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар» сүзләрен өстәргә»;

1 пунктта «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе»ДБББУ сүзләреннән соң «, шулай ук «Лениногорск

балалар йорты» ДБУнән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар» сүзләрен өстәргә.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» МКУ Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетында әлеге карарның 1 пунктында каралган максатларга акчалар табарга.

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 01 сентябреннән хокук мөнәсәбәтләренә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Советының социаль һәм милли мәсьәләләр, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр сәясәте буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Советы рәисе

М.Н.Гирфанов